РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МИЧАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422055, Республика Татарстан, Сабинский район,
Село Старый Мичан , ул. Школьная , 12
тел. (84362) 42-3-31

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МИЧЭН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422055, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Иске Мичэн авылы., Мэктэп урамы, 12 йорт

тел. (84362) 42-3-31

e-mail: mich.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
27.11.2024

КАРАР
№22

Саба муниципаль районы Мичән авыл башкарма комитетының 25.01.2022 ел, №3 карары белән расланган торак урыннарына мохтаҗ буларак гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында.

РФ Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында " 15.08.2022 №1415 карары нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге башкарма комитетының «Торак урыннарга мохтаҗ буларак гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында " 25.01.2022 ел, №3 карары белән расланган торак урыннарга мохтаҗ буларак гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1. 3.3.2.1 пунктының унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "Төзелгән гаризаны формат-логик тикшерү гаризаның электрон рәвешендәге һәр кырын тутыру барышында орган билгели торган таләпләр нигезендә бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал гаризаның электрон рәвешендәге дөрес тутырылмаган кырын ачыклаганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында гаризаның электрон рәвешендәге мәгълүмати хәбәр аша хәбәр ителә»;

1.2. 2.6.1 пунктының 10), 15), 17), 18) пунктчаларында «Россия Федерациясе Пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча рәсми рәвештә халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Мичән авыл җирлеге башлыгы А.Ә.Гәрәев